**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

«27» февраль 2019 нче ел

№ 37

**«Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы нигезләмәне һәм белем алу рәвешләрен раслау хакында»**

Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру, шулай ук балаларны исәпкә алуны үткәрүдә катнашучы органнар, учреждениеләр һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлек тәртибен билгеләү максатларында, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 9 статьясындагы 1 пунктының 6 пунктчасына, 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга, 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы «Балигъ булмаганнарны күзәтүчелек һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» гы Федераль законга нигезләнеп, карар бирәм:

1. «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру һәм белем алу формалары турында» Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ башлыгы (А.Л. Еронтьевка) әлеге Нигезләмә белән муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләрен таныштырырга.

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Руководитель**
**Исполнительного комитета**
**Новошешминского муниципального района** **Р.Р. Фасахов**

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2019 нчы елның «27» февралендә
37 номерлы карары белән расланган

## Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә мәгариф турында"гы Федераль закон (соңрак кертелгән үзгәрешләр белән), 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы «Балигъ булмаганнарны күзәтүчелек һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында " гы Федераль законга нигезләнеп, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны ел саен шәхси исәпкә алуны гамәлгә ашыру максатларында (алга таба - төп белем бирү программалары), шулай ук балаларны исәпкә алуны оештыруда катнашучы органнар, учреждениеләр һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлек тәртибен билгеләү максатларында эшләнгән.

1.2. Әлеге Нигезләмә Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә төп белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибен һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан сайлап алынган белем алу формаларын билгели.

1.3. Гомуми белем алуга конституция хокукларын тәэмин итү максатларында, яшәү (тору) урыны буенча теркәлү булу - булмауга карамастан, Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшәүче (даими яки вакытлыча) яисә 0 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге булган барлык балалар да ел саен шәхси исәпкә алынырга тиеш.

1.4. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәҗбүри белем алырга тиешле балаларны ачыклау һәм исәпкә алу гамәлдәге законнар нигезендә балигъ булмаганнарны күзәтүчелек һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре белән берлектә гамәлгә ашырыла.

1.5. Әлеге Нигезләмә нигезендә балаларны исәпкә алу буенча мәгълүмат 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы "Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында"гы Федераль закон таләпләре буенча, конфиденциальлекне тәэмин итеп җыелырга, тапшырылырга, сакланырга һәм файдаланылырга тиеш.

1.6. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр гамәлдәге законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

## II. Төп белем бирү программалары буенча укырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен оештыру

2.1. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында (алга таба - мәгариф учреждениеләре) белем алырга тиешле балаларны исәпкә алу эшен Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф бүлеге (алга таба – Мәгариф бүлеге) гамәлгә ашыра.

Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында мәҗбүри белем алырга тиешле Балалар турында мәгълүматларның муниципаль базасы (алга таба текст буенча - муниципаль мәгълүматлар базасы) Мәгариф бүлеге тарафыннан алып барыла.

2.2. Балаларны исәпкә алуда түбәндәге оешмалар катнаша:

- "Яңа Чишмә РҮХ" ДАССОсы (килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә социаль яклау бүлеге (килешү буенча);

- опека һәм попечительлек бүлеге;

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми белем һәм урта гомуми белем программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмалары;

- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә: Яңа Чишмә муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, Яңа Чишмә муниципаль районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы (Балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлек), авыл җирлекләре администрациясе.

2.3. Мәҗбүри укытылырга тиешле балалар турында муниципаль мәгълүматлар базасын формалаштыру чыганаклары булып, тубәндәгеләр хезмәт итә:

2.3.1. белем бирү оешмаларының мәгариф оешмаларына беркетелгән территорияләр турында мәгълүматлары;

2.3.2. мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы оешмаларының агымдагы елда мәктәпкәчә белем алуны тәгәлләүче һәм 6 яшь 6 айга җиткән, киләсе һәм алдагы уку елларында 1 нче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар турында мәгълүматлар;

2.3.3. шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма фактта тиешле территориядә яшәүче балалар турында Сәламәтлек саклау учреждениеләре фельдшерлары, участок педиатрлары, фельдшерлары мәгълүматлары;

2.3.4. яшәү урыны яки тору урыны буенча балаларны теркәү турында мәгълүматлар (теркәлү карталары, йорт китаплары һәм тд.);

2.3.5. социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә; эчке эшләр органнарының балигъ булмаган хокук бозучылар өчен вакытлыча тоту үзәкләрендә; дәвалау-профилактика һәм башка балалар учреждениеләрендә булган балалар турындагы мәгълүматлар;

2.3.6. Эчке эшләр бүлегенең участок уполномоченныйларыннан алынган, шул исәптән яшәү урыны буенча теркәлмәгән, әмма фактта тиешле территориядә яшәүче балалар турында мәгълүматлар;

2.3.7. Яңа Чишмә муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләре мәгълүматлары.

2.4. Балалар турында шәхси мәгълүматларны үз эченә алган балалар турында мәгълүматлар туган еллары буенча алфавит тәртибендә формалашкан исемлек белән рәсмиләштерелә.

Әлеге мәгълүматлар ел саен уку елы башында белем бирү оешмалары җитәкчеләре имзасы һәм оешма мөһере белән расланып кәгазь чыганакта мәгариф бүлегенә оешма җитәкчесе тарафыннан бирелә. Өстәмә мәгълүмат ел дәвамында бирелергә мөмкин.

## III. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында белем алырга тиешле балаларны ачыклау һәм исәпкә алу

3.1. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы оешмада йөрүче балаларның агымдагы исәбен алып бара.

3.2. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмасы ай саен «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү» муниципаль казна оешмасына балалар булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тәрбияләнүчеләрнең йөреш табельләрен, балаларны кабул итү һәм исәптән төшерү турында приказларның күчермәләрен тапшыра.

3.3. Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмасы җитәкчесе, гамәлдәге законнар нигезендә, балаларны агымдагы исәпкә алу буенча белешмәләрнең дөреслеге, балалар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) турындагы мәгълүматның конфиденциальлеге өчен җаваплы була, оешма эчендә мәгълүматны җыю, саклау, тапшыру һәм яклау турында тиешле локаль актлар чыгара.

3.4. Мәгариф бүлеге ел саен 1 сентябрьгә һәм 1 гыйнварга кадәр Яңа Чишмә муниципаль районының балалар дәвалау-профилактика оешмаларында күзәтелүче һәм исәптә торучы 0 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар санын билгеләү максаты белән "Яңа Чишмә РҮХ" ДАССОга мөрәҗәгать итә.

3.5. Мәгариф бүлеге түбәндәге балалар турында исәп алып бара:

- Яңа Чишмә районы территориясендә яшәүче балалар саны "Яңа Чишмә РҮХ" ДАССОда алынган мәгълүмат нигезендә дәвалау-профилактика учреждениеләрендә күзәтелүче һәм исәптә торучы 0 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар турында;
- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында урын бирү буенча электрон системадагы мәгълүматлар нигезендә («Электрон балалар бакчасы" АИС мәгълүмат системасы) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ

регламенты нигезендә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урын бирү буенча исәптә торучы балалар саны;

- мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалар саны.

## IV. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәҗбүри укытылырга тиешле балаларны ачыклау һәм исәпкә алу

4.1. Белем бирү оешмалары ел саен әлеге мәгариф оешмасына беркетелгән территориядә яшәүче 0-18 яшьлек балалар турында мәгълүматлар җыюны оештыра һәм гомумиләштерә):

- әлеге белем бирү оешмасында укучылар;
- башка белем бирү оешмаларында укучылар;
- башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар;
- уку елы башына 6 яшь 6 айга җиткән һәм киләсе һәм аннан соңгы уку елларына беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле балалар;
- гомуми белемнәре булмаган һәм законы үтәмичә беркая да укымаган;
- өйдә торып укучылар;
- беркая да эшләмәүче һәм укымаучылар;

4.2. Балалар турында мәгълүматлар муниципаль базасын булдыру һәм алып бару максатларында муниципаль гомуми белем бирү оешмалары ел саен, кайда яшәүләренә карамастан, үз оешмалары укучыларының агымдагы исәбен алып баралар.

4.2.1. белем бирү оешмасы 1 сентябрьдән 15 сентябрьгә кадәр җәйге каникулдан соң укуга керешкән барлык укучыларның исәбен һәм исемлек составын тикшерә.

4.2. Оешмада укучыларны кабул итүнең исемлек составы оешма җитәкчесе боерыгы белән рәсмиләштерелә, бер үк вакытта оешманың алфавит китабына язу кертелә.

4.2.3. Укучылар исемлеге оешмада ел саен 1 сентябрьгә төзелә.

Белем бирү оешмалары алынган мәгълүматларны сәламәтлек саклау органнарында һәм (яки) теркәү учеты органнарында (паспорт-виза хезмәте, авыл җирлекләре администрацияләрендә - килешү буенча) һәм кирәк булганда, аларга беркетелгән территорияләрдә өйләр буенча йөреп төгәлләштерәләр.

Гомумиләштерелгән һәм төгәлләштерелгән мәгълүматлар мәгариф оешмасы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2.4 пункт таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелә һәм ел саен мәгариф бүлегенә билгеләнгән формада тапшырыла (әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы):

- 15 сентябрьгә булган мәгълүматлар буенча (уку елында җәйге каникуллардан соң укуга керешкән укучылар һәм шушы территориядәге укучыларның исемлек составын чагыштыру максатыннан).

4.3. Белем бирү оешмалары укучыларның агымдагы исәбен гамәлгә ашыралар, аларның кайда яшәү урыннарына карамастан, дәресләргә йөрүен даими тикшереп торалар, социаль адаптация проблемалары булган укучылар

белән үзләрен тоту, укыту, үсеше буенча индивидуаль профилактик эш алып баралар.

4.4. Уку елы дәвамында оешмага кабул ителүче һәм уку елы барышында күчеп китүче балалар турында мәгълүмат мәгариф бүлегенә ел саен 15 майга кадәр тапшырыла (әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы).

Белем бирү оешмасыннан 15 яшькә җиткән укучы чыгарылган очракта, белем бирү оешмалары мәгариф бүлегенә түбәндәге тәртиптә укучыны төшереп калдыру турында хәбәр итәләр:

1. 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 61 статьясының 4 п. нигезендә (25.12.2018 елгы ред.), белем бирү мөнәсәбәтләрен туктату өчен нигез булып, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың укучының әлеге оешмадан чыгарылуы турында күрсәтмә акты тора. Әгәр укучылар яки ата-аналар (законлы вәкилләре) белән түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында килешү төзелгән икән, белем бирү мөнәсәбәтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, мондый шартнамә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың әлеге оешмадан белем алучы укучының чыгарылуы турында күрсәтмә акты нигезендә юкка чыгарыла. Укучының белем бирү турындагы законнарда һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың локаль норматив актларында каралган хокук һәм вазыйфалары белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан чыгарылган көненнән туктала.

2. Белем бирү мөнәсәбәтләрен вакытыннан алда туктаткан очракта, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма өч көн эчендә әлеге оешмадан чыгарылган затка «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 60 статьясындагы 12 өлеше нигезендә уку турында белешмә бирә.

3. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма мәгариф өлкәсендә идарә итүче җирле үзидарә органына балигъ булмаганнарга дисциплинар җәза чарасы буларак чыгарылуы турында өч көнлек срокта хәбәр итәргә тиеш. Мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы һәм балигъ булмаган баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) бер ай вакыт өчендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан чыгарылган балигъ булмаган баланың гомуми белем алуын тәэмин итүче чаралар күрергә тиеш.

4.5. 4.3 пунктында әйтеп үтелгән һәм 2.4 пункт таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән укучылар категорияләре турында мәгълүматлар белем бирү оешмалары тарафыннан Мәгариф бүлегенә ел саен 15 майга кадәр билгеләнгән формада бирелә (әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы).

4.6. Ел саен агымдагы елның 30 октябренә кадәр Мәгариф бүлеге район мәгариф оешмаларында белем алырга тиешле балалар турында мәгълүматлар базасы белән әлеге уку елында укуга фактик рәвештә керешкән балалар һәм балаларны кабул итүне тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгариф учреждениеләрендә фактта укырга керешкән укучылар турында мәгълүматлары белән чагыштыра.

Чагыштыру нәтиҗәләре турында мәгариф бүлеге белем бирү оешмаларына ел саен 5 ноябрьгә кадәр хәбәр итә.

4.7. Белем бирү оешмасы гражданнардан беркетелгән территориядә яшәүче һәм белем алырга тиешле балалар турында мәгълүмат кабул итүне оештыра.

Үз балалары тарафыннан белем алуга комачаулаучы гаиләләр ачыкланган һәм үз балаларын тәрбияләү һәм укыту буенча бурычларын тиешенчә башкармаган очракта, белем бирү оешмасы факт ачыкланган көннән соң бер эш көне өчендә:

- балигъ булмаганнарның укуын оештыру өчен ата-аналар (законлы вәкилләр) белән кичекмәстән эшчәнлек оештыра;

- мәгариф бүлегенә әлеге балаларның ачыклануы һәм андый балаларга белем бирүне оештыру буенча күрелгән чаралар турында хәбәр итә (кайсы датадан, нинди сыйныфта, уку формасы).

- бу хакта гамәлдәге законнар нигезендә йогынты чаралары күрү өчен балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиягә хәбәр итә.

4.8. Белем бирү оешмасы җитәкчесе гамәлдәге законнар нигезендә, мәгариф бүлегенә җибәрелгән балаларның агымдагы исәпкә алу буенча мәгълүматның дөреслеге өчен җавап тота, учреждениедә укучыларны исәпкә алу һәм йөртү буенча документларны, балалар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) турындагы мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итә, гамәлдәге законнар нигезендә оешма эчендә мәгълүматны җыю, тапшыру һәм саклау турында тиешле локаль актлар эзерли.

## V. Белем алу төрләрен исәпкә алу

5.1. Белем алу өчен түбәндәге формалардан файдаланырга мөмкин:

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш (гаилә белеме һәм үзлегеңнән белем алу рәвешендә).

Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә уку көндезге формада алып барыла. Киләчәктә арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен, гаилә белеме һәм үзлегеңнән белем алу рәвешендә укуга күчкән затларга белем бирү учреждениесен мөстәкыйль сайлап алу хокукы бирелә, яки мәгариф бүлеге аларны билгеле бер мәктәпкә беркетә.

5.2. Төрле формаларны чиратлаштырып белем алу һәм уку рөхсәт ителә.

5.3. Белем алу һәм уку формалары белем бирүнең һәр баскычы буенча төп белем бирү программалары тиешле федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән билгеләнә. Өстәмә белем бирү программалары буенча укыту формалары белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

5.4. Ата-аналар, төп гомуми белем алуны тәмамлаганчы, баланың фикерен исәпкә алып, шулай ук психологик-медицина-педагогик комиссия тәкъдимнәрен исәпкә алып белем алу формаларын һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны, алар тәкъдим иткән факультатив һәм электив предметларын, курслар, дисциплиналар (модульләр) сайлап алырга хокуклы.

5.5. Мәгариф бүлеге балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан сайлап алынган белем алу формаларын унсигез яше тулганчы алуларын исәпкә алып бара.

5.6. Унсигез яшькә җиткән балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре), укучы үзе мәгариф бүлегенә баланың гаилә белеме рәвешендә гомуми белем алу формасын сайлап алулары турында хәбәр итәләр.

5.7. Гомуми белем бирү оешмасы унсигез яшькә җиткән балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан сайланган урта белем алу формасы турында (гариза биргәннән соң өч көнлек срокта) мәгариф бүлегенә хәбәр итә.

## VI. Балаларны исәпкә алуны тәэмин итү буенча учреждениеләр һәм оешмалар компетенциясе

6.1. Мәгариф бүлеге:

6.1.1. Балаларны исәпкә алу эше буенча оештыру һәм методик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра.

6.1.2. Белем бирү оешмаларыннан, балалар турында әлеге нигезләмәнең 2.4 пункты таләпләренә туры китереп төзелгән мәгълүматны кабул итә һәм балалар турында муниципаль мәгълүматлар базасын формалаштыра.

6.1.3. Муниципаль базага кертелергә тиешле балалар турында мәгълүматны даими кабул итүне оештыра, нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгәнчә, учреждениеләр һәм оешмалардан алынган мәгълүмат нигезендә аңа төзәтмәләр кертүне үз вакытында гамәлгә ашыра.

6.1.4. Гомуми белем алмый торган балаларны кул астындагы белем бирү оешмаларына урнаштыруга чаралар күрә.

6.1.5. Белем алмавы турында билгеле булган балаларны укыга урнаштыру торышын контрольдә тота һәм муниципаль базага әлеге балалар турында тиешле үзгәрешләр кертә.

6.1.6. Балаларны укытуны оештыру һәм укучылар контингентын саклау буенча чаралар күрү буенча белем бирү оешмалары эшчәнлеген контрольдә тота.

6.1.7. Ведомство карамагындагы белем бирү оешмаларының тәрбияләнүчеләрне һәм укучыларны исәпкә алу һәм күченү буенча документлар алып бару эшчәнлеген контрольдә тота.

6.1.8. Муниципаль базага кертелгән балаларның гомуми белем алганчыга кадәр исемлеген саклауны гамәлгә ашыра.

6.2. Мәгариф оешмалары:

6.2.1. 0-18 яшьлек балаларны исәпкә алу эшен оештыралар һәм әлеге Нигезләмәнең 4 бүлеге нигезендә мәгариф булегенә мәгълүмат тапшыралар.

6.2.2. Укучылар белән даими рәвештә шөгыльләнүне тикшереп торалар, үзләрен тотуда, укытуда, үстерүдә һәм социаль адаптациядә проблемалары булган укучылар белән индивидуаль профилактик эш алып баралар.

6.2.3. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиягә укуга йөрми башлаган балалар турында хәбәр итәләр.

6.2.4. Белем алырга тиешле балаларның исемлеген һәм укучыларның төп гомуми һәм урта гомуми белем алганчы исәпкә алу һәм күченү буенча башка документларны саклауны тәэмин итәләр.

6.2.5. Балаларны исәпкә алу эше барышында ачыкланган гомуми белем алмаган балаларны укырга кабул итәләр.

3.3. Авыл җирлекләре башлыклары:

6.3.1. Әлеге Нигезләмәнең 3 бүлеге нигезендә балаларны исәпкә алу эшен оештыралар.

6.3.2. Балаларны исәпкә алу эшен башкарганда үзара хезмәттәшлек итү кирәклеге турында халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып баралар.

6.3.3. Үз территориясендә яшәүче гражданнардан укытылырга тиешле балалар турында мәгълүмат кабул итүен тәэмин итәләр.

6.3.4. Закон бозып укырга йөрмәүче балалар турында билгеле булган очракта, әлеге мәгълүматны язма рәвештә тиешле территориядә урнашкан мәгариф оешмаларына һәм мәгариф бүлегенә юллыйлар;

6.3.5. Үз компетенцияләре кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны, укучыларны социаль реабилитацияләүгә һәм аларны алга таба мәҗбүри укытуга юнәлдерелгән чаралар күрәләр.

6.4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә социаль яклау бүлеге (килешү буенча):

6.4.1. Социаль куркыныч яки авыр тормыш хәлендә булган балигъ булмаганнарга социаль хезмәтләр тәкъдим итә.

6.5. Сәламәтлек саклау учреждениеләре:

6.5.1. Ведомство карамагындагы учреждениеләрнең вазыйфаи затлары:

- "Яңа Чишмә РҮХ" ДАССОсы (килешү буенча)

мәгариф бүлеге һәм (яки) җитәкчеләр соравы буенча балалар халык санын алу мәгълүматларын тапшыралар.

6.6. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары:

6.6.1. Үз компетенциясе кысаларында мәгариф бүлегенә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында мәҗбүри белем алырга тиешле тиешле, ләкин гомуми белем алмаучы балалар турында мәгълүматлар җибәрәләр.

## VII. Җаваплылык

7.1. Белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре гамәлдәге законнар нигезендә балаларны исәпкә алу буенча мәгариф бүлегенә җибәрелә торган белешмәләрнең дөреслеге өчен; укучы, тәрбияләнүчеләрнең исәпкә алу һәм күченүләре буенча документларны тиешенчә алып баруы һәм саклануы; балалар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре), шул исәптән аларның шәхси мәгълүматлары турында мәгълүматның конфиденциальлеге өчен җаваплы.

7.2. Балалар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) турында, шул исәптән аларның шәхси мәгълүматлары турында мәгълүматның конфиденциальлеген бозган өчен, белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре гамәлдәге законнар нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылалар.

3.3. Мәгариф бүлеге, гамәлдәге законнар нигезендә, мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәҗбүри белем алырга тиешле балалар турында мәгълүматны җыю, саклау, куллану конфиденциальлеге өчен җаваплы.

## VIII. Йомгаклау нигезләмәләре

Нигезләмәгә өстәмәләр, шул исәптән Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсендәге гамәлдәге закончалыкларына узгәрешләр кергән очракта, Яңа Чишмә Башкарма комитеты җитәкчесе карары тарафыннан кертелә һәм расланалар.

Кушымта 1
Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешл балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәгә

**Белем бирү оешмасына беркетелгән территориядәге 0 дән 18 яшькәчә булган балаларның гомуми исемлеге**

______________________________
(уку йорты)

| № | ФИО | Туган елы, ае, көне | Тору урыны | Бүленеше (группа, сыйныф, уку йорты, эшли, эшләми, укымый) | Күчеп китү урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| Туган елы | | | | | |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| Туган елы | | | | | |
| | | | | | |

**Искәрмә:**
*** Нигезләмәнең 4.1 пункты нигезендә төзелә һәм Яңа Чишмә муниципаль районының мәгариф бүлегенә тапшырыла.**

Җитәкче

______________ (имза) ______________ (Ф.И.О.)

П.У.

Кушымта 2
Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешл балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәгә

**Дәресләрне системалы рәвештә калдыручы һәм уку йортыннан чыгарылган балалар турында мәгълүматлар**

______________________________
(уку йортынын исеме)

| № | Ф.И.О. | Туган вакыты | Группа, сыйныф | Сәбәпсезгә калдырылган дәресләр һәм көннәр саны | Дәрес калдыру сәбәпләре | Әлеге балага карата конкрет ай эчендә үткәрелгән профилактик чаралар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Искәрмә:
* Әлеге мәгълүмат ББО җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән тиешле срокларда тапшырыла.

Җитәкче

______________ ______________
(имза) (Ф.И.О.)

П.У.

Кушымта 3
Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешл балаларны исәпкә алуны оештыру турындагы Нигезләмәгә

**Укучыларның күчеше турында мәгълүматлар ________________ 20___елда:**

| | Сыйныфлар | 1 | 2 | 3 | 4 | 1 - 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 5 - 9 | 10 | 11 | 10 - 11 | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Группалар | | | | | | | | | | | | | | | |
| а | Отчет периодының башындагы балалар саны | | | | | | | | | | | | | | | |
| б | Барлыгы килүчеләр саны | | | | | | | | | | | | | | | |
| в | Барлыгы китүчеләр саны | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | Шул исәптән, ТР башка районнарына | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 | Районның башка урта белем бирү оешмаларында | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3 | Урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4 | Башлангыч һөнәри белем бирү | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләренд ә | | | | | | | | | | | | | | | |
| 5 | Укуны туктатып эшкә урнашучылар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6 | Башка уку төрләре | | | | | | | | | | | | | | | |
| 7 | Коррекцион ББО да укучылар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 8 | Интернат - мәктәпләрдә | | | | | | | | | | | | | | | |
| 9 | Балалар йортларындагы балалар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 10 | Эшләми һәм укымаучылар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 11 | Чыгарылганнар | | | | | | | | | | | | | | | |
| 12 | Авыру очрагы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 13 | Улем очрагы | | | | | | | | | | | | | | | |
| 14 | Республикадан чткә китүчеләр | | | | | | | | | | | | | | | |
| с | отчет периоды азагына укучылар саны | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче

_______________ (имза) _______________ (Ф.И.О.)

П.У.